Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 6 (6)

10 ноябрь 2011 ел

## ● Атнаның җиде вакыйгасы

8 ноябрь көнне университетка Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту буенча федераль хезмәт директоры Виктор Иванов килде. Аның белән берлектә ТР Премьер-министры Илдар Халиков, Татарстанда наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту буенча идарә җитәкчесе Фаяз Шабаев, ТРның Мәгариф һәм фән министры урынбасары Андрей Поминов һ.б. рәсми вәкилләр катнашты. Алар университет тарихы музее, мемориаль аудитория белән таныштылар.

• • • •

Казан федераль университетының карьераны планлаштыру буенча яшьләр үзәге чираттагы «Эшлекле дресс-код – карьера үсешенең сере» дип исемләнгән мастер-класс уздырды. Бүген һәр кешенең уңышы дресс-кодка нигезләнә. Оештыручылар да үзләренең тышкы-кыяфәте белән башкалардан аерылып тора иде. Үзәк җитәкчесе, аспирант Михаил Вавилин булачак дәүләт хезмәткәрләре һәм финансистларга лекция укыды. Яшьләр адвокатлар өчен кием сайлау, косметика һәм аксессуарлардан ничек итеп дөрес файдалану турында да фикер алыштылар.

• • • •

9 ноябрь көнне Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты базасында ТРның «Без...» яшьләр хәрәкәте активистлары «2013 елга 2013 литр кан» дигән акция уздырды. Әлеге хәрәкәт донорлыкны популярлаштыру белән 2005 елдан бирле шөгыльләнә. Казанда 8 зур масштаблы акция уздырылган инде. 200 студент тарафыннан 300 литр кан тапшырылган. Бу көнне дә һәр теләгән кеше, анкета тутырып, медицина тикшерүе узып, кан бирә алды. Барлык катнашучыларга да сертификат тапшырылды.

• • • •

11 ноябрьдә тантаналы рәвештә «Карагыз, бу – НАНО» дип исемләнгән күргәзмә ачыла. «Нанотехнологияләр атналыгы» проекты кысаларында булган һәм кызыклы нанотехнологияләргә багышланган күргәзмәне ачуда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Роснано» ААҖ рәисе Анатолий Чубайс катнашуы көтелә. Күргәзмә инфраструктуралы һәм белем бирү программалары фонды тарафыннан оештырыла. Биредә уникаль наноматериаллар, энергияне экономияләүгә караган перспективалы технологияләр, фәнни тикшеренүләр өчен кирәкле алдынгы җиһазлар тәкъдим ителә.

• • • •

Элеккеге Сәйдәшев урамы, 12нче йортта урнашкан «Бөтендөнья медицина инструментлары фәнни-тикшеренү проектлары институты» комплексы кысаларында Инжиниринговые үзәге ачу планлаштырыла. Әлеге институтның гомуми мәйданы 7400 кв.м. булган өч бинасы Казан федераль университетына тапшырылды. Биредә фәнни-технологик үзәкләр ачылачак. 20 ел дәвамында «Энергобанк» Акционерлык-коммерция банкы арендага алып торган Карл Маркс урамы, 43нче йортта урнашкан элеккеге КДФИИ бинасының беренче каты кире кайтарылды. Ул капиталь ремонтка мохтаж.

• • • •

Бу атнада фәлсәфә факультеты күченде. Алар Пушкин урамы, 1/55нче йортка урнашты. Бирегә күптән түгел Көнчыгышны өйрәнү институты күчкән иде. Сул Болак урамы, 34нче йортта урнашкан бинадан физика-математика факультеты да күчеп китте. Ә алар урынына География һәм экология институты күченде.

• • • •

Бүгеннән КФУда программалаштыру буенча Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты тарафыннан оештырылган V ачык олимпиада башлана. Программалаштыру өлкәсендә студент-яшьләрнең әзерлеген камилләштерү, әлеге юнәлештә сәләтлеләрне барлау һәм үстерү, программалаштыру белән бәйле һөнәрләргә карата кызыксыну уяту максатыннан оештырылган олимпиада кысаларында быел тәүге тапкыр өлкән сыйныф укучылары өчен иҗади атналык уздыру да планлаштырыла.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Спорт фестивале

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Казан университеты – Россиянең иң борынгы уку йортларының берсе. Яңа стиль белән 1804 елның 17 ноябрендә Император Александр I тарафыннан Указга кул куела. Университетыбыз быел зур үзгәрешләр белән 207 еллык Туган көнен каршы ала.

Ел дәвамында спортка, сәламәт яшәү рәвешенә бәйле рәвештә бик күп чаралар уздырыла. Университет бәйрәме уңаеннан, Федераль университетлар арасындагы студентлар спорты фестивале – сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм студентларның физик әзерлеген үстерү максатыннан үткәрелә торган чара.

Фестиваль ике этаптa уза. Беренче этап – 2011 елның сентябрь-октябрь айларында һәр вузда спорт чаралары үткәрелде, биредә тәркемнәр, курслар, факультетлар ярышты. Икенче этап (финал этабы) ноябрьдә Казан (Идел буе) федераль университетында уза.

Катнашучылар җиңел атлетика, өстәл теннисы, волейбол (кызлар), йөзү, кул көрәше, катнаш эстафета кебек спорт төрләре буенча көч сынаша алачак. Фестивальнең икенче этабына үткән командалар бердәм формадан булырга тиеш.

17-18 ноябрьдә фестиваль кысаларында «Студентны шәхес буларак тәрбияләүдә физик культура һәм спортның ролен үстерү» дигән Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узачак. Конференциянең пленар утырышы КФУның Актлар залында үтә. Чарада югары уку йортында физик тәрбиянең әһәмияте, спорт өлкәсендә һөнәри белем бирү үсешенең перспективалары һәм проблемалары, 2013 елда узачак Универсиадага әзерлек турында фикер алышулар планлаштырыла. «Сәламәт яшәү рәвеше алып бара торган вуз» конкурсы җиңүчеләре булган Себер федераль университеты, Томск политехник милли-тикшеренү университеты, Россия халыклар дуслыгы университетының эшчәнлекләрен чагылдырган презентация дә көтелә. Шулай ук Казан шәһәре буенча экскурсия дә оештырылачак.

Фестивальдә җиңүчеләрне кыйммәтле бүләкләр, диплом-грамоталар һәм медальләр көтә.

## ● Алар бездә укыган

# Яна – янә чемпион

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

Йөзү буенча Волгоградта үткән Россия чемпионатында якташыбыз Яна Мартынова беренчелекне алып кайтты.

400 метр араны комплекслы йөзү буенча ярышта Татарстан спортчысына тиңнәр табылмый. Россия җанатарлары Яна Мартынова турында беренче тапкыр 2004 елда ишетте. Нәфис гәүдәле мәктәп укучысы Афинада узган Олимпия уеннарында йөзү буенча милли команда составына эләгә. Шул көннән «Рубин» футбол командасының элеккеге капитаны Валерий Мартынов кызы, илдәге рекордлар санын яңартып, инде ничә тапкыр пьедесталның югары баскычына менде.

Россия чемпионы һәм рекорд куючысы Яна 2007 елда Дөнья чемпионатында көмеш, 2008 елда Европа чемпионатында бронза медаль яулый, 2011 елда икенче тапкыр Россия чемпионы исеменә лаек була.

Яна быел КДФИИның менеджмент факультетын тәмамлады. Кечкенәдән табиб яисә журналист булырга теләгән Яна: «Үземнең ничек менеджмент белгечлеген сайлавымны аңлатып бирә алмыйм», – ди. Киләчәктә тагын бер югары белем алырга хыяллана.



● Галимнәребез

# Докторның да мактаулысы

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче



КФУның Филология һәм сәнгать институты каршында эшли торган татаристика, тюркология һәм этномәдәни белем бирү үзәге җитәкчесе, күренекле галим, профессор Мирфатыйх Зәкиев шушы көннәрдә бер төркем Татарстан галимнәре белән Уфада булып кайтты. Анда танылган башкорт галиме, язучы, профессор Җәлил Киекбаевның 100 еллыгы билгеләп үтелде.

М.Зәкиев электән ТДГПУның мактаулы профессоры, Төркия тел җәмгыятенең мактаулы әгъзасы, Казакъстандагы Евразия университеты тюркология һәм алтаистика үзәгенең мактаулы әгъзасы санала. Хөрмәтле профессорыбызны Уфага бу килүендә Башкорт дәүләт университеты үзенең мактаулы докторы итеп сайлады. М.Зәкиевнең Ж.Киекбаев турында «Дәртле йыр» китабының өченче басмасы да чыгарылган. Ә Башкорт академиясе галимнең «Этногенез тюрков, булгар и башкир» дигән китабын бастырган.

Әлеге үзара хезмәттәшлек 1957 елдан бирле бара инде. Казан дәүләт университетында М.Зәкиев тарафыннан 1960 елны беренче татар теле кафедрасы оештырылганнан соң, КДУ һәм БДУ студентларына махсус курсларны М.Зәкиев белән Ж.Киекбаев алмашлап укыта торган була.

● Фән дөньясында

# «Туган тел каннан дәшә...»

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

Галимнәр 1999 елда Будапештта уздырылган Бөтендөнья фәнни конференция барышында Фән көнен үткәрергә кирәк дигән тәкъдим белән чыгалар. Шул рәвешле, 2002 елдан бирле 10 ноябрьдә Бөтендөнья фән көне билгеләп үтелә. ЮНЕСКО бу көнне бөтен дөнья буенча мәгариф үзәкләре, мәктәп, югары уку йортларында ачык ишекләр көне, «түгәрәк өстәл»ләр, семинарлар үткәрүне максат итеп куя.

Бүген, ягъни Бөтендөнья фән көнендә Казан федераль университетында халыкара фәнни конференция үз эшен башлап җибәрә. «Чит тел буларак Россия һәм якын чит илләрдә яшәүче халыкларның телләре: укыту һәм өйрәнү» дип аталган конференция 10-11 ноябрь көннәрендә Филология һәм сәнгать институтында уза.

Университетта мондый конференциянең әле беренче тапкыр гына үткәрелүе. Аны рус теле кафедрасы, тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара бәйләнышлар бүлеге, ТР Министрлар кабинеты белән берлектә үткәрәләр. Оештыру комитеты рәисе – фәнни эшләр буенча проректор, филология фәннәре докторы, профессор Данис Нургалиев. Конференциядә чит телле аудиториядә төрле телләрне укыту өлкәсенә зур өлеш керткән галимнәр катнаша.

Конференциянең тематикасы Казан университеты өчен гадәти түгел, чөнки үзләренең тәҗрибәләре белән рус һәм татар телле укытучы-галимнәр генә түгел, украин, корея, казакъ һ.б. телләрне укыту өлкәсендәге белгечләр дә үзләреннән зур өлеш кертә. Россиянең төрле фәнни үзәкләреннән, шулай ук якын һәм ерак чит илләрдән – Украина, Казакъстан, Германия, АКШ, Бөекбританиядән дә кунаклар чыгыш ясый. Чит телле аудиториядә белем биреп, инде күп еллар буена тәҗрибә туплаган галимнәр янәшәсендә яңа гына эшли башлаган яшь белгечләргә дә үз докладлары белән чыгыш ясау мөмкинлеге тудырылган.

Пленар утырышта профессор, КФУның Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, профессор, рус телен чит тел кафедрасы буларак нигезләүче Эмилия Балалыкина, МДУ профессорлары Елена Бархударова һәм Татьяна Владимирова, шулай ук Кырым институты ректоры, профессор Александр Рудяковның чыгышлары көтелә.



Конференция кысаларында 2 ноябрь көнне татар теленнән рус телле студентлар өчен узган вузара олимпиаданың нәтиҗәләре дә игълан ителде. Иң югары күрсәткечләргә КФУ Алабуга филиалының технологик-икътисади дизайн факультеты студенты Екатерина Максимова һәм Казан дәүләт медицина университетының педиатрия факультеты студенты Татьяна Кузьмина иреште. Аларның гомуми баллары – 79. Бер генә баллга калышып, КФУның Көнчыгышны өйрәнү институты студентлары Анастасия Лобова, Елена Ларионова, Елена Буканова шулай ук җиңүчеләр исемлегенә керде. Күрсәткечләре 64 баллдан 69 баллга кадәр булган Анастасия Мартынычева (КФУ), Юлия Егорова (КДТУ), Екатерина Ширяева (КФУ), Ольга Осипова (КДТУ), Екатерина Фадеевалар (КФУ) да бүләкләнүчеләр арасында.

Күренекле балалар шагыйре Шәүкәт Галиев үзенең бер китабында болай язган иде: «Лагерьдән кайткач, бер кыз әнисенә әйткән: «Бер генә татарча шигырь дә өйрәтмәгәнсез. «Һәркем үз туган телендә шигырь сөйләсен», – диделәр. Шулхәтле хурландым – чит ил балалары да бар иде. Алар да татарча белә». Шуннан соң өйрәнә башлый кыз. Үзе теләгән кешенең каныннан дәшә ул туган тел!» Әйе, чит телләрне өйрәнү – заман таләбе! Тик туган телебезне онытмыйк!

● Эшлекле сөйләшү

# Киләчәкне кайгыртып

**Анна КИРПИЧНИКОВА,**
**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрчеләр

9 ноябрь көнне уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов Тарих институтының гыйльми советында, География һәм экология институтының хезмәт коллективы конференциясендә; фәнни эшләр буенча проректор Данис Нургалиев А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты хезмәткәрләре җыелышында катнашты.

Укытучы-галимнәр игътибарына КФУ кичерә торган үзгәрешләр турында әзерләнгән «Үсеш программасы - хәрәкәттә» дигән фильм тәкъдим ителде.

География һәм экология институтының хезмәт коллективы конференциясендә уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов үз чыгышында бу институтның Болак буенда ике катлы бинасы төзелә башлаячагы һәм бай тарихы булган Обсерватория язмышы турында сөйләде. «Сезне партнерлар итеп күрәсебез килә. Булган проблемаларны үзара бергәләп чишәргә кирәк. Атна саен үткәрелә торган ректорат утырышында студентлар да, укытучы-галимнәр дә катнаша ала. Биналар мәсьәләсен уку елы дәвамында хәл итеп бетерербез, дип ышанам», – диде. Институтның стратегик мәсьәләләренә, заманча проектлар эшләүнең әһәмияте, хезмәт хакы һәм башкаларга тукталды ул.



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

География һәм экология институты директоры, профессор Олег Ермолаев уку йортының киләчәктәге планнары, структурасы белән таныштырды.

КДУның география факультетында озак еллар нәтиҗәле эшчәнлекләре өчен бер төркем укытучы-галимнәрне бүләкләү булды. Ахырдан 24 ноябрь көнне узачак конференциягә делегатлар сайлау үткәрелде.

Катнашучылар проректорларга үзләрен кызыксындырган сорауларны бирде. Аларны бигрәк тә Институтларның үсеше һәм техник яктан тәэмин ителеше кызыксындырды.

● Халыкара КВН көне

# Күңелле уен

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Шатлыклы һәм чын күңелдән көлү гомерне озынайта, диләр. Андый көлү тормыштагы иң күңелсез мизгелләрне онытырга да, кәефне күтәрергә дә ярдәм итә. Шатлыклы елмаюларсыз безнең көннәр караңгы һәм бертөрле генә узар иде. Арабызда эчебез катканчы, күздән яшьләр чыкканчы көлдерердәй, проблемаларны оныттырырдай кешеләр дә шактый. Әлбәттә, алар – КВНщиклар!

2001 елның 8 ноябре көнендә беренче мәртәбә Халыкара КВН көнен Россия һәм БДБның берничә иле билгеләп уза. Әлеге бәйрәмне үткәрү идеясен халыкара КВН клубы президенты Александр Масляков тәкъдим итә. Датаны да очраклы рәвештә генә сайлап алмыйлар. 1961 елда бу көнне Шаяннар һәм тапкырлар клубы үзенең беренче мәртәбә эфирга чыга башлауларының бер еллыгын билгели. Шаяннар һәм тапкырлар клубы халыкка күңелле мизгелләр бүләк итә. Елдан-ел клуб илебезне көлү белән тәэмин итүче командалар белән тулылана. Аларның «ачы» теленә студент тормышы да, танылган сәясәтчеләр дә, башка төрле вакыйгалар да эләгә. Берничә мәртәбә цензурага эләккән шаяруларны башта кисеп ташлыйлар, 1971 елда тапшыруны бөтенләй ябалар. Ләкин 1986 елда КВН үз эшчәнлеген торгызып җибәрә һәм халыкны яңадан-яңа чыгышлары белән сөендерә башлый. Алар Россия белән генә чикләнеп калмыйча, Европа илләрен, Американы яулый. Ләкин халыкара КВН көне БМОның бөтендөнья бәйрәмнәр исемлегенә кертелмәгән, шулай ук Россиянең рәсми бәйрәме итеп тә билгеләп үтелми.

КВН уеннары кагыйдәләре һәркемгә яхшы таныш: исәнләшү, разминка, СТЭМ, БРИЗ, музыкаль конкурс һәм өй эшеннән тора.

КВН уенчылары өчен – ул яраткан эш, күпмедер дәрәҗәдә бизнес, кемнәрдер өчен язмыш. Ә тамашачылар өчен - бик якты һәм онытылмас тамаша.

● Аталар сүзе – акылның үзе

# «Исән-сау йөреп кайтырга...»

Сәхифәне филология фәннәре кандидаты
**Луиза ҖАМАЛИЕВА** алып бара

Көз, яз житсә, унсигез яшь тулган егетләрнең һәм аларның әти-әниләренең башларына уй төшә. Ни дисәң дә, хәрби хезмәткә чакырылыш башлана бит. Бу уку елында оештырылган фольклор практикасы материаллары арасында хәрби хезмәткә озату белән бәйле йолалар хакында шактый бай мәгълүмат тупланды.

Материаллар Татарстанның төрле районнарында тупланса да, аларның эчтәлеге, нигездә, бертөрле. Хәрби хезмәткә чакырылу турында хәбәр килгәч, егетнең әти-әнисе аны юлга әзерли башлый. Егет кайдадыр укыса – укудан, эшләсә – эшеннән азат ителә. Хәбәр алганнан киткәнчегә кадәр, ул некрут булып йөри. Дус-ишләре белән авыл урамнарын җырлап әйләнү, авылдашлар белән саубуллашып йөрү һәр төбәктә дип әйтерлек бар. Гадәттә, җәяү йөреп, җырлый-җырлый урам әйләнәләр. Мамадыш районы Яңа Комазан авылында җәяү түгел, ике ат җигеп, җәен арбага утырып, кыш көне чанада узалар. Егет яшендәге бөтен кыз дип әйтерлек аңа кульяулык чигеп бүләк итә. Шуларны бер-берсенә төенләп бәйләп, егетнең муенына элеп куялар. Апас районында шундый бер ышану яши: әгәр бергә бәйләнгән кулъяулыкларның берәрсе төшеп калса, егет армиядә хезмәт итү срогыннан алданрак кайта икән.

Армиягә озату белән бәйле бәйрәмне кайсыдыр якта озату кичәсе дип, күпчелек очракта мәҗлес дип, ә менә Апас районы Дүртиле авылында «Алка» дип атыйлар икән. Әлеге бәйрәм егет иртәгә китәсе дигән көндә оештырыла. Бу мәҗлескә егетнең классташлары, дуслары, туганнары чакырыла. Егеткә бүләккә кызлар кулъяулык чигеп бирә, урам әйләнгәндә, өлкән апалар акча бирә. Егетне төрле бәла-казалардан саклап йөртсен дип, аңа догалар язылган бөтиләр тегеп бирү дә күп төбәкләрдә сакланып калган.

Юлга чыгар алдыннан, егеткә ипи каптырып, калганын, төреп, мич башына алып куялар. Ул шунда кибеп, сохарига әйләнә. Егет кайтканчы шунда тора. «Ризыгы туган нигезгә тартып тора», диләр. Егет киткән көнне идән юарга, себерергә ярамый. Аны озаткач, әби-бабайларны чәйгә чакыралар, исәнлегенә дога кылалар. Күп кенә авылларда егетләр авыл башындагы агачка берәр кулъяулык бәйләп калдыра.

Озату вакытында башкарылган җырларның текстлары бик үзенчәлекле:

*Военкомат янса иде,*
*Комиссарлары белән.*
*Армиягә китсәң иде,*
*Сөйгән ярларың белән.*

*Военкомат баскычларын*
*Таптамам дигән идем,*
*Туган-үскән авылымны*
*Ташламам дигән идем,* – дип ямансулый егетләр.



Егетнең дуслары да теләкләрен җырга сала:

*Кулымдагы йөзегемнең*
*Исемнәре Фатыйма.*
*Исән йөреп, сау кайтыгыз,*
*Бездән хәер-фатиха.*

Озату кичәсе шулай, солдат егеткә изге теләкләр теләп, таңгача дәвам итә. Кунаклар таң алдыннан гына тарала. Икенче көнне егетне озатырга тагын яшьләр җыела. Егетне яше-карты, әти-әнисе, туганнары, дуслары авыл башына тикле озата баралар.

Хәрби комиссариатка килеп җиткәч, армиягә китүче егетне, уртага алып, күккә чөяләр, җырлыйлар:

*Военкомат ишегалды –*
*Яшел чирәм үсмәгән.*
*Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,*
*Анда туып үсмәгән.*

*Бакчадагы алмагачка*
*Ике тасма бәйләнсен.*
*Исән-сау йөреп кайтырга*
*Ходай насыйп әйләсен.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, рекрут җырларын берничә төркемгә бүләргә мөмкин. Беренчеләрендә, хәрби хезмәткә алыну вакыты җиткәнне аңлап, якыннар белән аерылуга борчылу кебек хисләр өстенлек итә. Икенчеләрендә – армиядәге тормышны күз алдына китерү, андагы һәм мондагы тормышны чагыштыру. Кайбер җырларда аерылуның, гаиләнең башка вәкилләренә караганда, бала белән ана өчен авыр булуы турында сөйләнә, сөйгән ярларның егетнең кайтканын көтәчәгенә ышаныч белдерелә.

Егет китүгә, аннан хатлар көтә башлыйлар. Хатларда солдатлар, гадәттә, әти-әнигә, якын туганнарга гына түгел, авылдагы бөтен кешегә сәлам юллый. Кайберләрендә җыр текстлары да урын ала:

*Өстәлләрдә пыяла,*
*Ватма, җаным, уала.*
*Ташламам, бәгърем, ташламам!*
*Ташлар диеп уйлама.*

*Солдат, мескен, постта тора,*
*Шинельләрен ябынып.*
*Аягүрә төшләр күрә,*
*Сөйгән ярын сагынып.*

Соңгы елларда армиягә китүчеләр саны аз булса да, хәрби хезмәткә бәйле фольклор бүгенге көнгәчә сакланып калган һәм кулланыла дип әйтә алабыз.

● Халыкара бәйләнешләр

# 2 яшьтән – инглиз теле

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Һәр кеше үз кимчелеген яхшы белә. Мин менә күп телләр белгән кешеләрдән ак көнләшү белән көнләшәм. Аларга сокланып карыйм. Казан федераль университеты Алабуга филиалының чит телләр факультеты студенты Гүзәл Батдалова 4 телдә иркен аралаша. Укудан тыш, бию, рәсем сәнгате белән шөгыльләнә. Студент кыз инглиз һәм немец теле укытучысы булырга әзерләнә. Алган белемнәрен тагын да камилләштерү, чит илдә педагогик тәҗрибә булдыру максатыннан, Гүзәл Кытайда стажировка үтеп кайтты.

***– Гүзәл, Кытайга ничек барып эләктең?***

– Бүгенге көндә чит илләргә барып, стажировка үтү өчен, күп төрле программалар бар. Миңа Кытайның Шанхай шәһәрендә инглиз теле укытучысы вакансиясен тәкъдим иттеләр. Быел V курста белем алам. Киләчәктә үземне бары тик чит телләр укытучысы буларак кына күрәм. Шуңа күрә бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмадым.

***– Димәк, кытайларга инглиз теле серләрен өйрәттең?***

– Бакчада әле туган телендә дә сөйләшә белмәгән 2 яшьлек балалар инглиз телен өйрәнә башлый. Кайбер мәктәпләрдә хәтта бөтен предметлар әлеге телдә укытыла. Мин үзем дә балалар белән эшләдем. Алар белән бергә картина күргәзмәләренә, галерея, зоопарк, музейларга йөрдем. Бу шәһәрне һәм аның истәлекле урыннарын күрү өчен дә менә дигән мөмкинлек булды.

***– Истәлекле урыннар дигәннән, нәрсәсе белән җәлеп итә Кытай шәһәрләре?***

– Яшеллеге белән!!! Биредә экологиягә зур игътибар бирелә. Шанхай әкияти шәһәр булып исемдә калды. Ял итәргә кая барыйм икән дип уйлап утырасы да юк. Өй янында гына бакчада йөреп керергә мөмкин. Урамнарда безгә таныш булмаган яшелчә һәм җиләк-җимешләр үсеп утыра. Кытайлар моны җылы климат белән бәйләп аңлата. Җәй көне температура 40тан да түбән төшми. Карлы кышның ни икәнен бөтенләй белмиләр, чөнки кыш көне иң салкын һава – минус ике. Кешеләр дискомфорт кичерә, шуңа күрә бөтен җирдә кондиционерлар эшли, хәтта метрода да.

***– Юлдагы бөкеләрне җиңү юлларын уйлап тапмаганнармы соң әле?***

– Шанхайда Пекинга караганда да күбрәк халык яши. Машинаның күплегеннән күзләр чагыла. Бөкеләрдә утырмас өчен, эшкә кадәр скутер һәм велосипедларда баруны кулайрак күрәләр. Моның өчен юлда хәтта махсус полоса булдырылган.

***– Кытай халкы турында ни әйтерсең?***

– Кытайлар – бик дус һәм эшчән халык. Нәрсә генә сорап килсәң дә, бик теләп җавап бирәләр. Юлда адашып калган вакытлар да булды. Бөтен эшләрен ташлап, сиңа ярдәмгә ашыгалар. Кытайга баргач, югалырмын дип борчылмагыз!

***– Димәк, син кытай телен дә беләсең?***

– Кызганычка каршы, мин кытайча иркен сөйләшмим. Ләкин анда торган вакытта кирәк сүзләрне өйрәнеп калдым. Кайбер авазларны әйткәндә, «телең сынарга» мөмкин. Грамматикасы рус теленеке белән охшаш. Ләкин язылышын өйрәнү өчен, шактый вакыт кирәк, чөнки анда хәрефләр түгел, ә иероглифлар. Киләчәктә бу телне дә яхшылап өйрәнергә телим. Безнең илдә моның буенча белгечләр бик кирәк.

***– Милләттәшләребезне очрату насыйп булмадымы соң?***

– Татарларны бер генә мәртәбә дә күрмәдем, ләкин руслар гел очрап торды. Башка илләрдән килгән туристларны да күрдек. Урумчи дигән шәһәрдә рәхәтләнеп рус телендә аралашырга мөмкин, анда сине барсы да аңлаячак. Кунакка гына килгән, бөтенләй күченгән якташларыбыз да бар. Кире кайту турында уйлаучы да юк: «Без мондагы яшәү шартларыннан канәгать. Халкы да игътибарлы, көнләшүче, сиңа начарлык теләүче юк. Һәркайда якты йөз белән каршы алалар», – диләр. Безгә дә Кытайда калырга тәкъдим иттеләр.



***– Әгәр чын-чынлап шундый мөмкинлек булса, нишләр идең соң?***

– Туган илемдә калыр идем. Бездә дә, үзеңне күрсәтү, рәхәтләнеп яшәү өчен, бөтен шартлар да тудырылган. Хәзер барыбыз да чит илләргә күчеп китеп яши башласак, бездә ни булыр соң? Әлбәттә, мондый мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк, ләкин алар һәркайсы безнең файдага булсын! Шуңа күрә яшьтәшләремә әйтәсем килә: вакытыгызны бушка үткәрмәгез! Артык телләр, башка милләтләрнең мәдәниятен, гореф-гадәтләрен белү, белем эстәү беркемгә дә комачауламый.

# Кара көчләр бәйрәме

**Алсу НУРГАТИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты



*Берсеннән-берсе шомлы рәсемнәр, тәрәзә өлгесеннән тар салкынлык саркып чыга, искән җилдә бүлмә почмагындагы пәрәвез җепләре селкенеп куя, диварда төрле куркыныч игъланнар балкый... Тик, шуңа да карамастан, бу бүлмәдә бер көтү студент бәйрәм итә. Бу нинди бәйрәм дисезме?! Күптән түгел Универсиада авылының 16нчы йортында Хэллоуин булып узды.*

*Хэллоуин татар халык бәйрәме түгел дип кырт киссәк тә, бүген инде ул башкалабыз студентларының бергәләп уздыра торган бәйрәмнәренең берсе булып тора. Бәйрәм итәргә җыелганнар арасында төрле милләт вәкилләре катнаша.*

*Без яшәгән йортта Хэллоуин була дигән хәбәр ишеткәч сөенеп куйдым. Чөнки башка йортларда ул күңелле генә узды, без дә моны көткән идек. Күпләр белгәнчә, бу бәйрәмгә һәр кеше бер «кара көч» образын тудырып килергә тиеш. Арабызда төрле убырлылар, кара көчләрнең патшалары булу бәйрәмебезгә күңеллелек өстәде. Хэллоуин турында төрле куркыныч хәбәрләр йөрсә дә, бу көнне бөтен студент та туйганчы күңел ачты. Бәйрәм җырлы да, биюле дә булды. Берсеннән-берсе күңелле уеннар бер мәлдә зачет, параларны оныттырып торды. Ә бәйрәм ахырында тамаша барышында иң матур образ тудырган студентка грамота тапшырылды. Студентлар бәйрәмне чәй өстәле янында дәвам итте.*

*Тамашадан соң куркыныч образлар 16нчы йорт халкын бәйрәм белән котлап, куркытып йөрдек. Күп бүлмәләрдә булып, шундый нәтиҗәгә килдек: «ач студент»ны берни дә куркыта алмый икән!*

*P.S. Университетта уза торган чараларны оештыру буенча җаваплы студентлар безне әле алда берсеннән-берсе тагын да күңеллерәк бәйрәмнәр көтә дип шатландырды.*

Илһам канатында



**Рәмил Рәдиф улы МӨГЫЙНОВ** 1995 елнын 18 февралендә Яр Чаллы шәһәрендә дөньяга килә. Рәмил кечкенә чакта әтисенен туган ягы – Минзәлә районы Дәвек авылына күчеп кайталар. Бүген 10 сыйныфта белем ала. Иҗат белән бишенче сыйныфтан мавыга. Өч ел рәттән безнен университетта уздырыла торган «Илһамлы каләм» әдәби әсәрләр конкурсында анын хикәяләре призлы урыннар яулый. Кыска һәм тирән мәгънәле хикәяләренен берсен сезгә тәкъдим итәбез.

# Каравылчы оныгы

Төнгә каршы күк йөзен томалап килгән болыт каравыл өе эченә караңгылык тутырды. Тыштагы көчле җил тавышы, тәрәзәгә бәрелгән алмагач ботагының кыштырдавы шом өстәде. Ул арада тәрәзә пыялаларына беренче тамчылар килеп бәрелде.

Аптырау катыш курку белән бу тамашаны күзәтеп утырган Инсафка да кагылган кебек булды зилзилә. Аның бөтен тәне буйлап ниндидер бер салкын йөгереп үтте. Ул чытырдатып күзләрен йомды һәм бабасының тизрәк керүен теләде. Бабасы исә, икмәк тутырылган амбар ишекләрен җил каермасын тагын дип, ындыр башына киткән иде.

Әле биш яшен яңа тутырган Инсаф, бабасына ияреп, еш килә каравылга. «Мин барында безгә берәү дә кагыла алмый, әйеме, бабакай?» – ди ул, аңа сыенып һәм, сүзләрен раслап, әтисе ясап биргән агач мылтыгына карап куя.

Инсаф күзен ачмакчы булган иде, кинәт сызылган яшен яктысыннан куркып китте. Тәрәзә пыяласын зыңгылдатып, күк күкрәгән тавыш ишетелде. Ул да булмады, җил йолкуга түзәлмичә, тәрәзәнең бер ягы ачылып китте,бабасы яндырып калдырган шәм капыл сүнде. Инсафның тырышып-тырышып ясаган рәсемнәре туздырып, идән тулды.

«Шәмне сүндерә күрмә, улым, безнең маяк булыр ул», – дип китте бит бабасы. «Шәм янмагач, бабай ничек күрә инде өйне?» – дигән уй малайны



батырайтып җибәрде. Ул, барып, тәрәзәне япты, караңгыда кармалана-кармалана, өстәлдәге шырпы кабын эзләп тапты. Башка вакыт булса, билгеле, аны утка якын да китермәсләр иде, тик бүген ул бабакаен коткарырга тиеш…

Әллә ничә шырпыны сындырганнан соң, ниһаять, Инсаф шәмне кабызды. Өй эче яктырып китте. Тик бертуктаусыз уйнаган яшен артыннан дөмбердәгән тавышка һич күнегеп булмый. Малай, куркуын басар өчен, аякларын бөкләп, караватка менеп утырды да башыннан ук юрган бөркәнде. Болай иткәч, бераз тынычлана төште.

Инсафка вакыт бик озак үткән кебек тоелды: бабасын көтә-көтә арып бетте. Ниһаять, ишек ачылды, бабасының көр тавышы ишетелде.

– Яңгыры шәп, улым, бәрәкәтле. Амбарларга су тулмасын дип, ерганакларны тирәнәйтеп йөрдем, – диде ул, ишек янындагы урындыкка утырып. Өй эченә яңгыр исе таралды. Инсаф аның янына йөгереп килде, киемнәрен салырга булышты.

– Бабай, син маякка карап кайттыңмы? – дип сорады ул. Бабасы:

– Әйе, улым, тышта берни күрерлек түгел бит алайса, – диде һәм аны җылы йомшак куллары белән кочаклап алды.

Халәт

# …китап киштәсе

**Алсу НУРГАТИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

Казан диген син, ә?! Ничәнче көн инде дәреслеккә эш дәфтәре эзлим, таба алмыйм. Нинди генә китап кибете калмады… Бауман урамнарындагы китап киштәләрен актардым, «Божра»дагы сатучыларны аптыратып бетердем, «Сувар Плаза» үзәгеннән эзләп карадым – юк!

Кибеткә килеп керүең була, борынга яңа китаплар исе бәрелә. Үзенә бертөрле ләззәт белән киштәләр арасында йөрисең. Өрјаңа, әле табадан төшкән китапларны карап сокланасың. Кайсыларын ачып укыган буласың, кайберләренең бәяләрен күргәч, кире куеп китү ягын карыйсың. Бүгенге көндә китап яратучылар сирәк дисәң дә, бар әле алар. Ничә кибеткә кердем, буш түгел иделәр, әдәби китаплар янында иҗатка битараф булмаганнар шәйләнә. Әле менә бер апа кочагы белән китап сатып алды. Күбесе – әдәби китаплар. Бу чын китап яратучыдыр инде, дип уйлап куйдым эчтән генә. Күпчелек дәреслекләр янына береккән. Авылда укыганда да, югары уку йортына кергәч тә әллә ни күп китап сатып алмадык диярлек. Һәр дәреслек – матур гына бәядән! Китапханәдән алган белем чишмәләренең кадерләрен белергә кирәк. Иң күп сатыла торган китаплар да әдәби чыганаклар булып чыкты. Сатучылар әйтүенчә, халык дәреслекләрдән



башка әдәбият белән дә кызыксына икән! Монысына бар күңелем белән сөенеп куйдым!

Китап киштәләре арасыннан үзеңә кирәкле бүлекне эзләп табасың. Сиңа дигән китап – юк! Күзеңә кайчандыр бик кирәксенеп эзләгән китаплар да шәйләнеп кала. Сиңа дигәндә, юк шул алар.

…Инде ничәнче кибет бусагасын таптыйм.

– Сездә дәреслекләргә эш дәфтәрләре бармы?!

– Бар!

– 5 сыйныф, «Табигать белеме».

– Авторлары?

– Плешаков, Сонин…

– Кызганыч, беткән.

Өметеңне өзеп чыгып китәсең. Аннан икенчесенә, өченчесенә керәсең…

– Гафу итегез, Плешакин, Сонов, «Табигать белеме»…

– Нинди-нинди авторлар?!

– Плешаков, Сонин…

Монда да булмады. Сеңлемә кирәкле шул дәфтәрне эзләп бер көнем үтеп китте… Булмады, тапмадым. Казан диген, ә?! Бер дәфтәр табып булмый. Бер «Табигать белеме», йолкыш дәфтәр! Эх…

Туганнан-туган апаларга барырга дип чыккан идем, автобус тәрәзәсеннән чираттагы «Китап йорты» шәйләнеп калды. Кире кайтканда, Арбузов тукталышыннан туп-туры шунда юнәлдем.

– Исәнмесез, дәреслекләргә эш дәфтәрләре бармы?

– Бар, авторы кем?

Инде ятлап, төшләремә кереп, телгә бәйләнеп беткән шул ике фамилияне атадым…

– Бар!

Кит аннан! Киштә арасыннан мин күпме тилмереп эзләгән шул дәфтәр килеп чыкты. Сатучы апаны кочаклап алуымны сизми дә калдым. Таптым бит, таптым! Бер булмаса, бер була икән. Казан диген, ә?!

Апа минем шатланганны күреп көлемсерәп куйды. Бүләккә Казанның бар китап кибетләренең адреслары, телефон номерлары язылган буклет та кыстырып җибәрде. Рәхмәт әйтеп, канатланып, урамга йөгердем.

Телефоным сеңлемнән сөенче алырга ашыкты…

Рульдә - бичә

# 4 тапкыр сүнде!!!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче



КУЛДА МАШИНА ЙӨРТҮ ТАНЫКЛЫГЫ БУЛГАЧ, АНЫ ШКАФТА ТУЗАН ҖЫЙДЫРЫП ЯТКЫРАСЫ КИЛМИ БИТ ИНДЕ. НИШЛӘРГӘ ХӘЗЕР? ЯРАР, СУМКАМА САЛЫП ЙӨРЕРМЕН ИНДЕ… ШУНЫҢ ӨЧЕН УКЫДЫММЫ МИН? ЮК, БОЛАЙ БУЛМЫЙ БУ… БЕР-БЕР НӘРСӘ УЙЛАРГА, МӘСЬӘЛӘНЕ УҢАЙ ЯККА ХӘЛ ИТӘРГӘ КИРӘК.

Озак уйлап тормадык, сеңлем белән машина алырга булдык. Кесәдә ник сукыр бер тиен булсын! Киттек автосалонга, машинаның да иң текәләрен карыйбыз. Сатучылар безне бай дип уйлады, ахры. Хәтта йөреп карарга да тәкъдим иттеләр. Без инде, әлбәттә, үзебезнең «бай» студентлар икәнне әллә ни сиздермичә генә: «Без абыебыз белән киләбез, рәхмәт», – дип кайтып киттек. Кызларның шул инде аның, башына керсә, мәңге кире чыгарам димә! Нәтиҗәдә: «Әлегә ярар», – дип, без тотылган машина алырга булдык. Иң кызыгы: безнең бу карар турында әнкәй берни дә белми!!!

Машина эзләү, аны сатып алу, номер алу турында аерым язма эшләргә кирәк. «Безнең бүген 300 чакрым кайтасы бар, соңга кала алмыйбыз», – дип, полицейский абыйларны да селкетеп алдым. Алар нибары 3 ай элек таныклык алып, әле бер мәртәбә дә руль артына утырып карамаган ике блондинка кайтуын белми шул.

…Без юлга чыкканда, сәгать кичке 6 тулып киткән иде. Бәйрәм алды җомгасы, Сабантуйлар көтә. Юлдагы бөкене әйтеп тә, аңлатып та бетереп булмый. 2 сәгать ярым дигәндә, Казанны чыгып киттек. Шул арада машина 4 тапкыр сүнәргә өлгерде. Кирегә юл юк, кайтасы да кайтасы… Ярты юлга да җитмәдек, бик көчле давыл башланды. Дөм караңгы М7 трассасы буенча кечкенә тимер атыбыз алга җилдерә. Мин күк күкрәүдән, көчле яшеннән бик куркам. Сиздерергә ярамый, эчтән догаларымны укыйм, күздән яшь ага. Үзем такмаклыйм икән: «Соңгы сәгатьләрем җиткәндер инде…»

Гарасат туктагач, юлыбызны дәвам иттек. Юл тыныч, алай машиналар да күп түгел. Мамадышның «Макдолнадс»ына җиткәч: «Эх, өчпочмак белән чәй эчеп алырга», – дигән сүзләрне әйткәнгә кайтып җиткәнче үкенергә туры килде. Чаллы, Менделеевск районнарын үтеп, Удмуртиянең Алнаш районы буйлап кайтабыз (М7 трассасы буенча йөрүчеләр бу маршрутны яхшы белә). Сеңлем йоклап китәм, йоклап китәм, дип кайта инде… Менә шул вакыт килеп чыкмасынмы каршыга поши! Кая ул йокы килү!!!

Пошидан калган шок хәле белән авылга кайтып җиткәнне сизми дә калдык. Куркулар, каушаулар артта… Тимер атыбыз белән ишек алдына кереп туктадык. Матур итеп җәйге таң атып килә. Сәгать иртәнге өченче ярты… Әтәчебез кычкырып каршы алды. Ә әнкәебез сабый йокысы белән йоклый иде… Безне күргәч, ике күзе дүрт булды. Беренчедән, ул безнең кайтасыны белми иде. Ә машинаны күргәч, бөтенләй телсез калды… Үземне йокысыннан айнып бетмәгән әнкәй урынына куеп карарга курыктым. Ул ни еларга, ни көләргә белмичә бик озак басып торды. Күзләрендә аның безнең өчен горурлык хисләре белән бергә ниндидер аңлашылып бетми торган караш иде…

Сәламәтлек

## *Томаудан*

*Халык арасында таралган бер чараны искәртеп үтик: терсәкләрне кайнар су агып торган кран астына тыгалар. Кулларны (терсәккә кадәр) сулы ләгәнгә тыгып утырырга да ярый. Суның температурасы куллар түзә алырлык булсын. Бу процедураны мөмкин кадәр ешрак ясарга кирәк. 1-2 көннән томау бетә.*

## *Гәүдәнең артык авырлыгыннан котылу өчен*

*2 атна дәвамында көнгә 3 тапкыр ашарга 1 сәгать кала яңа гына әзерләнгән кишер-кәбестә (1х1) согы һәм 30 минут кала солы-гөлҗимеш төнәтмәсе эчегез. Әлеге диетаны тотканда, ит, камыр ризыкларын куллану тыела. Кичләрен 1 сәгать буена башта акрын, аннары кызу адымнар белән урамда йөрергә, йокы алдыннан өстеңә җылы су коярга кирәк. Сок белән төнәтмәне 2 атна эчү, ә урамда йөрүне ай буе дәвам итү шарт. Шулай эшләсәгез, аена 10-15 кг авырлыктан котылырсыз.*

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла